ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 459-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 459-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ / ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2108-VI ДС

Проект

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $53^5$ статьяның 1 пунктында «һәм аларның структур элементлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 55 статьяның 2 пунктында:

а) беренче абзацта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының программаны раслаган норматив хокукый акты нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән дәүләт программаларының исемлеге һәм структурасы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) икенче абзацта «билгеләгән срокларда» сүзләрен «билгеләгән тәртиптә һәм срокларда» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Татарстан Республикасы дәүләт программалары агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына туры китерелергә тиеш.»;

3) $55^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

4) $55^2$ статьяның 2 пунктына:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче һәм бишенче абзацлар өстәргә:

«авыр йөк транспорт чаралары тарафыннан региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләүдән Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чаралары хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;»;

б) дүртенче – алтынчы абзацларны тиешенчә алтынчы – сигезенче абзацлар дип санарга;

5) $9^2$ кушымтаның 8 пунктында «чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга;

6) $9^{2.1}$ кушымтаның 6 пунктында «чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы законы» сүзләрен «чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы законы» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда «$31^{1.2}$ статьясындагы 3 пунктының,» сүзләреннән соң «32 статьясындагы 3 пунктының (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы дәүләт эчке хисаплашулары программасы өлешендә),» сүзләрен өстәргә, «43 статьясындагы бишенче абзацының (федераль законнарда билгеләнгән очракларда)» сүзләреннән соң «, $53^1$ статьясының, 61 статьясындагы 1 пунктының» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. 2023 елда Татарстан Республикасы Рәисе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына 2023 елның 30 октябреннән дә соңга калмыйча 2024 елга, 2025

һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын кертә дип билгеләргә.».

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $55^2$ статьясындагы 2 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеттан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясе аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) белән Россия Федерациясе Бюджет кодексына, шул исәптән Россия Федерациясе субъектының, Россия Федерациясе субъектының юл фондының дәүләт һәм ведомство максатчан программаларына кагылышлы өлешендә, үзгәрешләр кертелде.

Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы законы проекты белән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру тәртибен регламентлаучы Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясына үзгәрешләр кертү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программаларын агымдагы елның 1 апреленә кадәр агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына туры китерүнең конкрет срогын билгеләү тәкъдим ителә. Татарстан Республикасы бБюджет кодексының ведомство максатчан программалары турында $55^1$ статьясын үз көчен югалткан дип танырга тәкъдим ителә.

Шулай ук закон проекты белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $55^2$ статьясына үзгәрешләр кертү каралган, алар нигезендә 2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Юллар фондын төзү чыганакларына авыр йөк транспорт чаралары тарафыннан региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына китерелә торган зыянны каплау исәбенә түләүдән, шулай ук авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чаралары хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре кертеләчәк.

Федераль закон белән шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының кайбер нормаларын туктатып тору да каралган.

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү

хакында» 2022 елның 26 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Дәүләт Думасына 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына федераль бюджет турында федераль закон проектын кертү срогы 2023 елның 15 сентябреннән 2023 елның 1 октябренә күчерелүгә бәйле рәвештә, 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы бюджеты проектында федераль бюджеттан бюджетара трансфертларны исәпкә алу тулылыгы максатларында, 2023 елда Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 статьясында билгеләнгән Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каравына 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Бюджеты турында Татарстан Республикасы законын кертү срогын 2023 елның 15 октябреннән 2023 елның 30 октябренә күчерергә тәкъдим ителә.

Закон проектында Федераль законга туры килә торган һәм бюджет законнарын куллануны камилләштерүгә юнәлдерелгән, шул исәптән агымдагы финанс елына Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәлеше кысаларында, башка үзгәрешләр бар.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Татарстан Республикасы салым чыгымнары исемлеген булдыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 13 сентябрендәге 831 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү таләп итә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2023 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми һәм Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешенә йогынты ясамый.